КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 20 февраль г.Казань № 101

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 12 июнь, 493 нче карары белән расланган «Математика, табигый-фәнни һәм технологик профильләр предметларын тирәнтен өйрәнелә торган башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүнең мәгариф программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына ярдәм» гранты һәм аны бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Математика, табигый-фәнни һәм технологик профильләр предметларын тирәнтен өйрәнелә торган башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүнең мәгариф программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына ярдәм» гранты һәм аны бирү тәртибе турында» 2021 ел, 12 июнь, 493 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 13 апрель, 453 нче; 2023 ел, 19 сентябрь, 1152 нче; 2024 ел, 7 октябрь, 861 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Математика, табигый-фәнни һәм технологик профильләр предметларын тирәнтен өйрәнүче башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына ярдәм» гранты һәм аны бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә, аны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итеп, үзгәреш кертергә.

2. Бу карарның гамәле 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 21 июнь, 493 нче карары белән расланды
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 ел, 20 февраль, 101 нче карары редакциясендә)

«Математика, табигый-фәнни һәм технологик профильләр предметлары тирәнтен өйрәнелә торган башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүнең мәгариф программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына ярдәм» гранты һәм аны бирү тәртибе турында
нигезләмә

I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга, шулай ук товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүче физик затларга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан, җирле бюджетлардан субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне һәм әлеге субсидияләрне, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантларны алучыларны сайлап алуны үткәрүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләрне раслау турында» 2023 елның 25 октябрендәге 1782 номерлы карары, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә эшләнде һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан «Математика, табигый-фәнни һәм технологик профильләр предметлары тирәнтен өйрәнелә торган башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүнең мәгариф программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына ярдәм» грантын (алга таба – грант) бирү шартларын һәм тәртибен билгели.

1.2. Россия Федерациясенең бюджет законнары нигезендә бюджет акчасын алучы буларак тиешле финанс елына грант бирүгә бюджет йөкләмәләре лимитлары билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет акчасы белән баш эш итүче функцияләрен гамәлгә ашыручы дәүләт хакимияте органы – Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы (алга таба – Министрлык).

1.3. Грант бирүнең максаты – математика, табигый-фәнни һәм технологик профильләр предметлары тирәнтен өйрәнелә торган башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүнең мәгариф программаларын гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы мәгариф оешмаларына ярдәм күрсәтү.

1.4. Сайлап алуны уздыру ысулы – грант бирү нәтиҗәсенә ирешүнең иң яхшы шартларыннан чыгып, грант алучыны билгеләүдән торган конкурс (алга таба – сайлап алу).

1.5. Грант турында мәгълүмат «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе бюджет системасы бердәм порталының (алга таба –

бердәм портал, «Интернет» челтәре) «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.

1.6. Сайлап алу «Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең дәүләт интеграцияләнгән мәгълүмат системасында (алга таба – «Электрон бюджет» системасы) гамәлгә ашырыла.

1.7. Министрлыкның һәм заявкаларны карап тикшерү һәм бәяләү комиссиясенең (алга таба – конкурс комиссиясе) сайлап алуда катнашучылар белән үзара хезмәттәшлеге «Электрон бюджет» системасында электрон рәвештә документлардан файдаланып гамәлгә ашырыла.

1.8. Сайлап алуда катнашучыларның «Электрон бюджет» системасыннан файдалану мөмкинлеге «Дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктурада идентификация һәм аутентификация бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып гамәлгә ашырыла.

1.9. Грант алучының категориясе – Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан, математика, табигый-фәнни һәм технологик профильләр предметлары тирәнтен өйрәнелә торган башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүнең мәгариф программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган бюджет учреждениесе яисә автоном учреждение булган югары белем бирү мәгариф оешмасы (алга таба – сайлап алуда катнашучы);

1.10. Грант бирү ысулы – чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү.

## II. Грант бирү шартлары

2.1. Финанс белән тәэмин итү чыганагы грант булган чыгымнар юнәлешләре:

математика, табигый-фәнни һәм технологик профильләр предметлары тирәнтен өйрәнелә торган башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүнең мәгариф программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмалары эшчәнлеген финанс белән тәэмин итү;

математика, табигый-фәнни һәм технологик профильләр предметлары тирәнтен өйрәнелә торган башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүнең мәгариф программаларын гамәлгә ашырганда мәгариф оешмаларының педагогик коллективын һөнәри үстерү һәм аның квалификациясен күтәрү;

интеллектуаль конкурсларда һәм халыкара, бөтенроссия һәм төбәк дәрәҗәләрендәге ярышларда катнашу нәтиҗәләре буенча педагогик коллективны матди бүләкләү.

2.2. Грант түбәндәгеләргә юнәлтелә алмый:

әлеге Нигезләмәнең 1.3 пунктында күрсәтелгән максатларны гамәлгә ашыруга турыдан-туры бәйле булмаган хезмәт күрсәтүләргә һәм эшләр башкаруга;

юридик затларга, физик затларга, индивидуаль эшкуарларга ярдәм күрсәтүгә;

алкогольле һәм тәмәке продукциясе, шулай ук зиннәтлелек предметлары булган товарлар сатып алуга;

сәяси партияләрне, кампанияләрне һәм акцияләрне финанслауга, митинглар, демонстрацияләр, пикетлар әзерләүгә һәм үткәрүгә;

бурычларны каплауга;

штраф түләүгә.

2.3. Грантның күләме 250 966,6 мең сум тәшкил итә. Ел саен сайлап алу йомгаклары буенча бер грант бирелә.

2.4. Грантны бирү нәтиҗәсе – түбәндәге күрсәткечләргә комплекслы ирешү:

математика, табигый-фәнни һәм технологик профильләр предметлары тирәнтен өйрәнелә торган башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүнең мәгариф программаларын үзләштергән укучылар санын грант алучыда белем алучыларның гомуми саныннан кимендә 80 процент саклап калу;

аерым предметлар буенча мәктәп укучыларының бөтенроссия олимпиадасында, башка интеллектуаль конкурсларда һәм төрле дәрәҗәдәге ярышларда җиңгән һәм бүләкләнгән белем алучыларның өлешен грант алучыларда белем алучыларның гомуми саныннан кимендә 5 процент күләмендәге күрсәткечкә арттыру;

төп гомуми һәм урта гомуми белем бирүнең мәгариф программалары буенча дәүләт йомгаклау аттестациясенең йомгаклары буенча югары нәтиҗәләргә ия белем алучыларның өлешен грант алучыда белем алучыларның гомуми саныннан кимендә 10 процент күләмендәге күрсәткечкә кадәр арттыру.

Грант бирү нәтиҗәсенә грант бирелгән уку елының 31 августыннан да соңга калмыйча ирешелергә тиеш.

## III. Сайлап алуда катнашучыларга карата таләпләр

3.1. Заявканы карау һәм грант бирү турында килешү (алга таба – килешү) төзү даталарына карата сайлап алуда катнашучы түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

чит ил, шул исәптән Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория теркәлү урыны булып торган юридик зат, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (Россия Федерациясе законнары белән башкасы каралмаган очракта) булып тормый. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статуслы) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;

экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы барлыгы турында белешмәләр булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

БМО уставының VII бүлегендә каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру кысаларында БМО Куркынычсызлык Советы яки БМО Куркынычсызлык Советы карарлары белән махсус оештырылган органнар тарафыннан төзелә торган

террорчылык оешмалары һәм террорчылар белән яки массакүләм юк итү коралын тарату белән бәйле оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

әлеге Нигезләмәнең 1.3 пунктында билгеләнгән максатлар өчен Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алмый;

«Чит ил йогынтысында булган затлар эшчәнлеген контрольдә тоту турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил агенты булып тормый;

бердәм салым исәбендә Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләү буенча бурычы булмый яисә Россия Федерациясе Салым кодексының 47 статьясындагы 3 пунктында билгеләнгән күләмнән артмый;

башка субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча срогы чыккан бурычы, шулай ук Татарстан Республикасы алдында акчалата йөкләмәләр буенча башка срогы чыккан (җайга салынмаган) бурычы булмый (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән очраклардан тыш);

үзгәртеп оештыру (сайлап алуда катнашучыга кушу, башка юридик затка кушу формасында үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында тормый, аңа карата банкротлык процедурасы билгеләнми, сайлап алуда катнашучы эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмый;

дисквалификацияләнгән затлар реестрында дисквалификацияләнгән җитәкче, коллегиаль башкарма орган әгъзалары, бердәм башкарма орган функцияләрен башкаручы зат яки сайлап алуда катнашучының баш бухгалтеры (булганда) турында мәгълүматлар булмый.

3.2. Сайлап алуда катнашучының әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшерү «Электрон бюджет» системасында сайлап алуны уздыруны тәэмин итә торган дәүләт мәгълүмат системалары (алга таба – дәүләт мәгълүмат системасы) белешмәләре нигезендә, шул исәптән ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасын кулланып, автомат рәвештә гамәлгә ашырыла.

Ведомствоара электрон хезмәттәшлек кысаларында Министрлыкның файдалану мөмкинлеге булган дәүләт мәгълүмат системаларында тиешле мәгълүмат булган очракта, Министрлык сайлап алуда катнашучының әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслый торган документларны тапшыруны таләп итәргә хокуклы түгел (сайлап алуда катнашучы әлеге документларны һәм мәгълүматны үз инициативасы белән Министрлыкка тапшырырга әзер булган очрактан тыш).

«Электрон бюджет» системасында автомат рәвештә тикшерүне гамәлгә ашыруның техник мөмкинлеге булмаган очракта, сайлап алуда катнашучының әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслау сайлап алуда катнашучы тарафыннан «Электрон бюджет» системасы веб-интерфейсының тиешле экран формаларын тутыру юлы белән әлеге таләпләргә туры килү-килмәү турында тамгаларны электрон рәвештә язып кую юлы белән гамәлгә ашырыла.

## IV. Сайлап алуны уздыру турында белдерүне формалаштыру һәм урнаштыру тәртибе

4.1. Сайлап алуны уздыру турында белдерү, «Электрон бюджет» системасында Министрлык белдерүне формалаштырган көннән алып бер календарь көннән дә соңга калмыйча, Министрлык җитәкчесенең (ул вәкаләт биргән затның) көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланып, бердәм порталда грант турында мәгълүмат басылып чыкканнан соң урнаштырыла.

4.2. Сайлап алуны уздыру турында белдерү Министрлыкның «Электрон бюджет» системасының веб-интерфейсның тиешле экран формаларын тутыру юлы белән электрон рәвештә формалаша, Министрлык җитәкчесенең (ул вәкаләт биргән зат) көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана, бердәм порталда бастырыла, түбәндәге мәгълүматны үз эченә ала:

сайлап алуны үткәрү сроклары;

заявкалар бирә башлау һәм кабул итү тәмамлану датасы, шул ук вакытта заявкаларны кабул итүнең тәмамлану датасы сайлап алуны уздыру турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 30 нчы календарь көннән дә иртәрәк була алмый;

Министрлыкның исеме, урнашу урыны, почта адресы, электрон почта адресы;

әлеге Нигезләмәнең 2.4 пункты нигезендә грант бирү нәтиҗәсе;

«Интернет» челтәрендәге дәүләт мәгълүмат системасының домен исеме һәм (яисә) битләре күрсәткечләре;

сайлап алуда катнашучы әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән даталарга туры килергә тиешле әлеге Нигезләмәнең 3.1 пункты нигезендә билгеләнгән сайлап алуда катнашучыларга һәм күрсәтелгән таләпләргә туры килүен раслау өчен конкурста катнашучылар тарафыннан тапшырыла торган документлар исемлегенә карата таләпләр;

грант алучының категориясе һәм бәяләү критерийлары, бәяләү критерийларының күрсәткечләре;

сайлап алуда катнашучылар тарафыннан заявкалар бирү тәртибе һәм әлеге Нигезләмәнең 6.1 – 6.5 пунктлары нигезендә заявкалар формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләр;

әлеге Нигезләмәнең 6.7 пункты нигезендә заявкаларны кире алу тәртибе, заявкаларны кире кайтару (шул исәптән заявкаларны кире кайтару өчен нигезләрне билгели торган) тәртибе, заявкага үзгәрешләр кертү тәртибе;

бу Нигезләмәнең 7.1 – 7.12 пунктлары нигезендә заявкаларны карап тикшерү һәм бәяләү кагыйдәләре;

эшләп бетерү өчен заявкаларны кире кайтару тәртибе;

заявкаларны кабул итмәү тәртибе, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 7.10 пункты нигезендә аларны кабул итмәү нигезләре турында мәгълүмат;

сайлап алуда катнашучы тарафыннан бәяләүнең һәр критерие буенча мәгълүматны тапшыру өчен кирәк бәяләү критерийларын һәм гомуми бәяләүдә аларның саллы әһәмиятен үз эченә алган заявкаларны бәяләү тәртибе, мондый мәгълүматны раслый торган белешмәләр, документлар һәм материаллар, заявкаларны бәяләү сроклары, шулай ук конкурс комиссиясенең һәм экспертларның (эксперт

оешмаларының) заявкаларны бәяләүдә катнашуы яисә катнашмавы турында мәгълүмат;

әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән сайлап алу кысаларында бүленә торган грант күләме, сайлап алуда җиңүчегә бирелә торган грантның максималь, минималь күләмен үз эченә алган сайлап алу нәтиҗәләре буенча грантны бүлү кагыйдәләре, шулай ук сайлап алуда җиңүчеләрнең иң чик саны;

сайлап алуда катнашучыларга әлеге Нигезләмәнең 6.9 – 6.11 пунктлары нигезендә сайлап алуны уздыру турында белдерү нигезләмәләренә аңлатмалар бирү тәртибе, мондый бирүне башлау һәм төгәлләү датасы;

сайлап алуда җиңүче әлеге Нигезләмәнең 8.1 пункты нигезендә килешүгә кул куярга тиешле срок;

сайлап алуны үткәрүне туктату тәртибе һәм очрагы, сайлап алу йомгаклары буенча килешү төзү очрагы һәм сайлап алу үткәрелмәгән дип тану очрагы;

сайлап алуда җиңүчене әлеге Нигезләмәнең 8.5 пункты нигезендә килешү төзүдән баш тарткан дип тану шартлары;

сайлап алуда катнашучыларның заявкаларын карап тикшерү һәм бәяләү йомгаклары буенча минималь үтү баллы;

бердәм порталда, шулай ук Министрлыкның «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында (https://mon.tatarstan.ru/) сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсен урнаштыру сроклары (ул сайлап алуда җиңүче билгеләнгән көннән соң килә торган 14 календарь көннән дә соңрак була алмый).

4.3. Сайлап алуны уздыру турындагы белдерүгә үзгәрешләр кертү, заявкаларны кабул итү тәмамлану датасыннан да соңга калмыйча, әлеге Нигезләмәнең 4.2 пунктында билгеләнгән сайлап алуны уздыру турындагы белдерүне формалаштыру тәртибе кебек тәртиптә, түбәндәге шартларны үтәп, гамәлгә ашырыла:

заявкаларны бирү срогы мондый үзгәрешләр кертелгән көннән соң килә торган көннән заявкаларны кабул итү датасына кадәр әлеге срок кимендә 10 календарь көн тәшкил итә торган итеп озайтылырга тиеш;

сайлап алуны уздыру турындагы белдерүгә үзгәрешләр кертелгәндә сайлап алу ысулын үзгәртергә рөхсәт ителми;

сайлап алуны уздыру турындагы белдерүгә үзгәрешләр кертелгән очракта, заявкалар кабул итә башлау датасы башланганнан соң, сайлап алуны уздыру турындагы белдерүгә сайлап алуда катнашучыларның әлеге Нигезләмәнең 6.8 пунктындагы беренче абзацы нигезендә заявкага үзгәрешләр кертү хокукы каралган нигезләмә кертелә;

заявка биргән сайлап алуда катнашучыларга, «Электрон бюджет» системасыннан файдаланып, сайлап алуны уздыру турындагы белдерүгә үзгәрешләр кертелгән көннән соң икенче көннән дә соңга калмыйча, сайлап алуны уздыру турындагы белдерүгә үзгәрешләр кертү хакында хәбәр ителә.

4.4. Сайлап алуны уздыруга үзгәреш кертү турындагы белдерү электрон рәвештә «Электрон бюджет» системасының веб-интерфейсның тиешле экран формаларын тутыру юлы белән төзелә, Министрлык җитәкчесенең (ул вәкаләт биргән затның) көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана, бердәм порталда урнаштырыла һәм сайлап алуны үзгәртү сәбәпләре турында мәгълүмат бирелә.

## V. Сайлап алуны үткәрүне гамәлдән чыгару тәртибе

5.1. Министрлык тарафыннан бердәм порталда сайлап алуны уздырмау турында белдерү урнаштыру сайлап алуда катнашучылар тарафыннан заявкаларны бирү срогы тәмамлану датасына кадәр бер эш көненнән дә соңга калмыйча рөхсәт ителә.

5.2. Сайлап алу үткәрүне гамәлдән чыгару турында игълан электрон рәвештә «Электрон бюджет» системасының веб-интерфейсның тиешле экран формаларын тутыру юлы белән төзелә, Министрлык җитәкчесенең (ул вәкаләт биргән затның) көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана, бердәм порталда урнаштырыла һәм сайлап алуны гамәлдән чыгару сәбәпләре турында мәгълүмат бирелә.

5.3. Сайлап алуны үткәрмәү очрагы – әлеге Нигезләмәнең 1.3 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Министрлыкка җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитларын кире алу.

5.4. Заявкалар биргән сайлап алуда катнашучыларга «Электрон бюджет» системасында сайлап алуны уздырмау турында мәгълүмат бирелә.

5.5. Сайлап алу бердәм порталда сайлап алуны үткәрмәү турында белдерү урнаштырылган көннән уздырылмаячак дип санала.

5.6. Әлеге Нигезләмәнең 5.1 пункты нигезендә сайлап алуны үткәрмәү срогы тәмамланганнан соң һәм сайлап алуда җиңүче белән килешү төзелгәнгә кадәр Министрлык Россия Федерациясе Граждан кодексының 401 статьясындагы 3 пункты нигезендә җиңеп булмый торган көч шартлары барлыкка килгән очракта гына сайлап алуны үткәрелмәскә мөмкин.

## VI. Сайлап алуда катнашучылар тарафыннан заявкалар булдырылу һәм бирелү тәртибе

6.1. Сайлап алуда катнашучы сайлап алуны уздыру турында игъланда күрсәтелгән срокларда заявканы «Электрон бюджет» системасының веб-интерфейсның тиешле экран формаларын тутыру юлы белән электрон рәвештә төзи һәм бирә һәм «Электрон бюджет» системасына документларның электрон күчермәләрен (сканлаштыру юлы белән электрон формага үзгәртелгән кәгазь чыганактагы документларны) тапшыра:

сайлап алуда катнашучы уставының гамәлдәге редакциясе;

коммерциячел һәм коммерциячел булмаган оешмалардан, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан ярдәм хатлары (иганәчелек хатлары) (булганда);

башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүнең мәгариф программалары буенча мәгариф эшчәнлеген алып баруга лицензия;

сайлап алуда катнашучының штат расписаниесе;

сайлап алуда катнашучының башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүнең мәгариф программасын гамәлгә ашыра торган бүлекчәсе турындагы нигезләмә;

белем алучыларның олимпиадаларда һәм башка интеллектуаль конкурсларда, математика, табигый-фәнни һәм технологик профильләр предметлары буенча мәктәп укучыларының халыкара, бөтенроссия, төбәк дәрәҗәләрендәге ярышларында катнашу нәтиҗәлелеген раслый торган документлар;

сайлап алуда катнашучының җитәкчесе (вәкаләтле заты) тарафыннан имзаланган, сайлап алуны уздыру датасына кадәрге соңгы өч уку елы өчен математика, табигый-фәнни һәм технологик профильләр предметлары тирәнтен өйрәнелә торган башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүнең мәгариф программалары буенча белем алучыларның арадаш һәм дәүләт йомгаклау аттестациясен уздыру йомгаклары турында белешмәләр бирелгән мәгълүмат характерындагы белешмә кәгазе;

сайлап алуда катнашучының җитәкчесе (вәкаләтле заты) тарафыннан имзаланган, сайлап алуны уздыру датасына кадәрге соңгы өч уку елы өчен математика, табигый-фәнни һәм технологик профильләр предметлары тирәнтен өйрәнелә торган башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүнең мәгариф программаларын гамәли тормышка ашыру нәтиҗәләре турында белешмәләр бирелгән мәгълүмат характерындагы белешмә кәгазе;

әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктында билгеләнгән таләпләргә сайлап алуда катнашучының туры килүен раслый торган, сайлап алуда катнашучының җитәкчесе (вәкаләтле заты) һәм баш бухгалтеры тарафыннан кул куелган мәгълүмати белешмә кәгазе;

сайлап алуда катнашучыны сайлап алуда катнашу өчен сайлап алуда катнашучыга карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы дәүләт хакимияте органының (дәүләт органының) һәм (яисә) җирле үзидарә органының ризалыгы.

6.2. Заявка сайлап алуда катнашучы җитәкчесенең яисә ул вәкаләт биргән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана.

6.3. Заявкадагы мәгълүматның һәм документларның тулылыгы һәм дөреслеге өчен, шулай ук аларны үз вакытында тапшыру өчен сайлап алуда катнашучы Россия Федерациясе законнары нигезендә җавап бирә.

6.4. Заявкага кертелә торган документларның һәм материалларның электрон күчермәләре барлык документны йә аның өлешен карау мәгълүматны карауны һәркем файдалана алырлык программа белән тәэмин итү чаралары белән карау мөмкинлеген тәэмин итә торган киң таралган ачык форматларга ия булырга тиеш һәм махсус программа яисә технологик чаралардан башка аларның эчтәлеге белән танышуны гамәлгә ашырырга мөмкинлек бирми торган чаралар белән шифрланган яисә саклаган булырга тиеш түгел.

Заявкага кертелә торган фото һәм видеоматериалларда сурәт югары сыйфатлы ачык һәм контрастлы булырга тиеш.

6.5. Сайлап алуда катнашучы тарафыннан заявка бирү датасы булып, заявкага «Электрон бюджет» системасында теркәлү номеры бирелеп, аңа имза куелган көн санала.

6.6. Заявкада түбәндәге белешмәләр булырга тиеш:

а) сайлап алуда катнашучы турында мәгълүмат һәм документлар:

сайлап алуда катнашучының тулы һәм кыскартылган исеме;

сайлап алуда катнашучының адресы;

элемтәгә керү өчен телефон номеры, почта адресы һәм юридик әһәмиятле хәбәрләр җибәрү өчен электрон почта адресы;

салым түләүченең баш бухгалтеры (булган очракта) коллегиаль башкарма орган әгъзалары, аерым хуҗалык башкарма органы функциясен үтәүче зат фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) һәм идентификация номеры;

сайлап алуда катнашучы җитәкчесе турында мәгълүмат (фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), салым түләүченең идентификация номеры, вазыйфасы);

сайлап алуда катнашучы оешманың гамәлгә кую документлары нигезендә гамәлгә ашырырга хокуклы эшчәнлекнең төп һәм өстәмә төрләре исемлеге;

грантны күчерү өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә счетлар турында, шулай ук килешүне имзалауга вәкаләтле зат турында мәгълүмат;

б) сайлап алуда катнашучының сайлап алуны уздыру турында белдерүдә билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслый торган мәгълүмат һәм документлар;

в) «Интернет» челтәрендә сайлап алуда катнашучы турында, сайлап алуда катнашучы тарафыннан бирелгән заявка турында, шулай ук «Электрон бюджет» системасы веб-интерфейсының тиешле экран формаларын тутыру юлы белән бирелә торган грантны сайлап алуга һәм аның нәтиҗәсенә бәйле рәвештә сайлап алуда катнашучы турында башка мәгълүматны бастырып чыгаруга (урнаштыруга) ризалыгын раслау;

г) әлеге Нигезләмәнең 2.4 пунктында күрсәтелгән грант бирү нәтиҗәсенең сайлап алуда катнашучы тарафыннан тәкъдим ителә торган күрсәткечләре, сайлап алуда катнашучы тарафыннан сорала торган грант күләменең сайлап алуны уздыру турындагы белдерүдә билгеләнгән максималь (минималь) күләмнән югары (түбән) була алмый торган күрсәткече;

д) сайлап алуны уздыру турында белдерүдә күрсәтелгән һәр бәяләү критерие, белешмәләр, документлар һәм материаллар буенча мондый мәгълүматны раслый торган мәгълүмат.

6.7. Сайлап алуда катнашучы заявканы сайлап алу тәмамланганга кадәр теләсә кайсы вакытта кире алырга хокуклы. Кирәк булганда сайлап алуда катнашучы заявкалар бирү өчен билгеләнгән срок эчендә кабат заявка бирергә хокуклы.

6.8. Заявкага үзгәрешләр кертү яки заявканы кире алу сайлап алуда катнашучы тарафыннан әлеге Нигезләмәнең 6.1 пунктында күрсәтелгән сайлап алуда катнашучы заявкасын формалаштыру тәртибендәге кебек тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Заявкага үзгәрешләр кертү сайлап алуда катнашучы электрон формада формалаштырылган заявкаларны кире алу турында хәбәрнамәдән һәм алга таба яңа заявка төзелгәннән соң заявкаларны кабул итү срогы тәмамланган көнгә кадәр гамәлгә ашырыла.

6.9. Теләсә кайсы сайлап алуда катнашучы бердәм порталда сайлап алуны уздыру турында белдерү урнаштырылган көннән, заявкалар тапшыру тәмамланган көнгә кадәр өченче эш көненнән дә соңга калмыйча, Министрлыкка «Электрон бюджет» системасында тиешле рәсми сорау формалаштыру юлы белән сайлап алуны уздыру турында белдерү нигезләмәләрен аңлату турында их күбе биш рәсми сорау

җибәрергә хокуклы.

6.10. Министрлык әлеге Нигезләмәнең 6.9 пунктында күрсәтелгән рәсми сорауга җавап итеп күрсәтелгән игълан белән билгеләнгән срокта, әмма заявкалар бирү тәмамланган көнгә кадәр бер эш көненнән дә соңга калмыйча тиешле аңлатманы «Электрон бюджет» системасында булдыру юлы белән сайлап алуны уздыру турындагы игълан нигезләмәләренә аңлатма җибәрә. Министрлык тарафыннан сайлап алуны уздыру турында белдерү нигезләмәләренә карата бирелгән аңлатма әлеге белдерүдәге мәгълүматның асылын үзгәртмәскә тиеш.

6.11. «Электрон бюджет» системасында формалаша торган аңлатмадан файдалану әлеге Нигезләмәнең 6.10 пункты нигезендә сайлап алуның барлык катнашучыларына бирелә.

## VII. Заявкаларны карау һәм бәяләү, шулай ук сайлап алуда җиңүчене билгеләү тәртибе

7.1. Заявкаларны карап тикшерү һәм бәяләү максатларында Министрлык конкурс комиссиясе төзи, аңа шул исәптән Министрлыкның иҗтимагый советы әгъзалары кертелә. Конкурс комиссиясе составы Министрлык боерыгы белән раслана.

7.2. Конкурс комиссиясе конкурс комиссиясе рәисеннән, конкурс комиссиясе рәисе урынбасарыннан, конкурс комиссиясе секретареннән, конкурс комиссиясе әгъзаларыннан төзелә.

Конкурс комиссиясенең эш тәртибе Министрлык боерыгы белән раслана.

7.3. Конкурс комиссиясе рәисе конкурс комиссиясе эшчәнлеге белән җитәкчелек итә, конкурс комиссиясе карарын раслый.

Конкурс комиссиясе рәисе булмаганда аның функцияләрен аның кушуы буенча конкурс комиссиясе рәисе урынбасары башкара.

Конкурс комиссиясе сәркатибе конкурс комиссиясе эшчәнлеген оештыру функцияләрен башкара.

7.4. Конкурс комиссиясе карарлары конкурс комиссиясе утырышында катнашучы әгъзаларның күпчелек тавышы белән ачык тавыш биреп кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта, рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була.

Конкурс комиссиясе утырышы, әгәр анда әгъзаларының кимендә яртысы катнашса, хокуклы дип санала.

7.5. Сайлап алуны уздыру турындагы белдерүдә билгеләнгән заявкалар бирү срогы тәмамланган көннән соң килә торган бер эш көненнән дә соңга калмыйча, «Электрон бюджет» системасында Министрлыкка, шулай ук конкурс комиссиясенә сайлап алучылар тарафыннан тапшырган заявкаларга аларны карап тикшерү һәм бәяләү өчен керү мөмкинлеге бирелә.

Заявкаларны карап тикшерү һәм бәяләү «Электрон бюджет» системасында заявкаларны карап тикшерү һәм бәяләү өчен Министрлыкка, шулай ук конкурс комиссиясе керү мөмкинлеге ачылган көннән соң килә торган 15 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

7.6. Конкурс комиссиясе, сайлап алуны уздыру турында белдерүдә билгеләнгән

заявкаларны ачу көненнән соң килә торган бер эш көненнән дә соңга калмыйча, заявкаларны ачу беркетмәсенә имза куя, анда сайлап алуда катнашу өчен кергән заявкалар турында түбәндәге мәгълүмат бирелә:

а) заявканы теркәү номеры;

б) заявка керү датасы һәм вакыты;

в) сайлап алуда катнашучының тулы исеме;

г) юридик затның адресы;

д) сайлап алуда катнашучы тарафыннан сорала торган грант күләме.

7.7. Заявкаларны ачу беркетмәсе бердәм порталда автомат рәвештә булдырыла һәм «Электрон бюджет» системасында конкурс комиссиясе рәисенең һәм конкурс комиссиясе әгъзаларының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана, шулай ук аңа кул куелган көннән соң килә торган бер эш көненнән дә соңга калмыйча бердәм порталда урнаштырыла.

7.8. Әгәр заявка сайлап алуны уздыру турындагы белдерүдә күрсәтелгән таләпләргә туры килсә һәм заявканы кабул итмәү өчен нигезләр булмаганда, ул дөрес дип таныла.

Сайлап алуны уздыру турындагы белдерүдә күрсәтелгән таләпләргә заявканың туры килүе-килмәве хакында карар конкурс комиссиясе тарафыннан сайлап алуда катнашучылар заявка белән бергә бирелгән мәгълүматны һәм документларны тикшерү нәтиҗәләре алынган көндә кабул ителә.

7.9. Заявка, әлеге Нигезләмәнең 7.10 пунктында каралган заявканы кабул итмәү өчен нигезләр булган очракта, кабул ителми.

7.10. Заявканы кабул итмәү өчен түбәндәгеләр нигез була:

сайлап алуда катнашучының әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

сайлап алуны уздыру турындагы белдерүдә күрсәтелгән документларның сайлап алуда катнашучы тарафыннан тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

сайлап алуда катнашучы тарафыннан тапшырылган документларның һәм (яки) заявканың сайлап алуны уздыру турындагы белдерүдә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

заявка составында сайлап алуда катнашучы тарафыннан тапшырылган документлардагы мәгълүматның дөрес булмавы;

сайлап алуда катнашучы тарафыннан заявканың аны бирү өчен билгеләнгән датадан һәм (яки) вакыттан соң бирелүе.

7.11. Заявкаларны карап тикшерү һәм бәяләү нәтиҗәләре буенча, заявкаларны карап тикшерү һәм бәяләү срогы тәмамланган көннән соң бер эш көненнән дә соңга калмыйча, заявкаларны карап тикшерү беркетмәсе әзерләнә, анда кергән һәм карап тикшерелгән заявкаларның саны турында мәгълүмат, шулай ук сайлап алуда катнашкан һәрберсе буенча аның заявкасын тиешле дип тану яисә, кире кагу өчен нигезләр күрсәтелеп, аның заявасын кире кагу турында мәгълүмат күрсәтелә.

7.12. Заявкаларны карап тикшерү беркетмәсе заявкаларны карап тикшерү һәм бәяләү нәтиҗәләре нигезендә бердәм порталда автомат рәвештә төзелә һәм «Электрон бюджет» системасында конкурс комиссиясе рәисенең һәм конкурс комиссиясе әгъзаларының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана, шулай

ук аңа кул куелган көннән соң килә торган бер эш көненнән дә соңга калмыйча бердәм порталда урнаштырыла.

Заявкаларны карап тикшерү беркетмәсенә үзгәрешләр кертү, мондый үзгәрешләр кертелү сәбәпләре күрсәтелеп, әлеге пунктның беренче абзацында билгеләнгән аны формалаштыру тәртибендәге кебек тәртиптә әлеге беркетмәнең яңа версиясен формалаштыру юлы белән заявкаларны карап тикшерү беркетмәсенең беренче версиясенә имза куелган көннән 10 календарь көннән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

7.13. Заявканы тулы, һәрьяклап һәм объектив карау һәм бәяләү максатларында үзләре тапшырган документлар һәм мәгълүмат буенча аңлатмалар алу өчен сайлап алуда катнашучыдан мәгълүмат һәм документлар алырга кирәк булган очракта, Министрлык, «Электрон бюджет» системасыннан файдаланып, документларга һәм мәгълүматка карата аңлатуны сайлап алуда катнашучылардан соратып ала, кирәк булса, сайлауда барлык катнашучыларга бертигез дәрәҗәдә җибәрелә.

7.14. Әлеге Нигезләмәнең 7.13 пунктында күрсәтелгән рәсми сорауда Министрлык сайлап алуда катнашучылар тарафыннан документларга һәм мәгүлүматка карата аңлатма бирү срогын билгели, әлеге срок тиешле рәсми сорау урнаштырылган көннән соң килә торган көннән кимендә ике эш көнен тәшкил итәргә тиеш.

7.15. Әгәр сайлап алуда катнашучы әлеге Нигезләмәнең 7.13 пунктында күрсәтелгән рәсми сорауга җавап итеп соратыла торган документларны һәм мәгълүматны, әлеге Нигезләмәнең 7.14 пункты нигезләмәләрен исәпкә алып, тиешле рәсми сорауда билгеләнгән срокта тапшырмаган булса, бу турыда мәгълүмат әлеге Нигезләмәнең 7.11 пунктында каралган заявкаларны карап тикшерү беркетмәсенә кертелә.

7.16. Сайлап алуда катнашучы әлеге Нигезләмәнең 7.14 пункты нигезләмәләрен исәпкә алып, тиешле рәсми сорауда билгеләнгән сроклар эчендә әлеге Нигезләмәнең 7.13 пункты нигезендә соратыла торган мәгълүматны һәм документларны булдыра һәм «Электрон бюджет» системасына бирә.

7.17. Сайлап алу түбәндәге очракларда үткәрелмәгән дип таныла:

а) заявкалар бирү срогы тәмамланган көнгә бер генә заявка да бирелмәгән;

б) заявкаларны карап тикшерү нәтиҗәләре буенча барлык заявкалар кабул ителмәгән;

в) заявкаларны бәяләү нәтиҗәләре буенча бер генә заявка да сайлап алуны уздыру турындагы белдерүдә билгеләнгән минималь үтү баллынна зурырак яисә аңа тигез балл җыймаган.

7.18. Заявкаларны бәяләү критерийлары һәм аларны бәяләү критерийлары буенча заявкаларны бәяләү күрсәткечләре

| Т/с | Заявканы бәяләү критерийлары | Бәя | Авырлык күрсәткече, процент |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Сайлап алуны үткәрү датасына кадәрге соңгы өч уку елында математика, табигый-фәнни һәм технологик профильләр предметлары тирәнтен өйрәнелә торган башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүнең мәгариф программаларының белем алучылар тарафыннан үзләштерелү нәтиҗәләренең уңай динамикасы | сайлап алуны уздыру датасына кадәрге соңгы өч уку елы өчен математика, табигый-фәнни һәм технологик профильләр предметлары тирәнтен өйрәнелә торган башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүнең мәгариф программаларын белем алучылар үзләштерү нәтиҗәләренең уңай динамикасы булу – 100 балл;<br>сайлап алуны уздыру датасына кадәрге соңгы өч уку елы өчен математика, табигый-фәнни һәм технологик профильләр предметлары тирәнтен өйрәнелә торган башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүнең мәгариф программаларын белем алучылар үзләштерү нәтиҗәләренең уңай динамикасы булмау – 0 балл; | 30 |
| 2. | Төбәк дәрәҗәсендәге математика, табигый-фәнни һәм технологик профильләр предметлары буенча олимпиадаларда һәм башка интеллектуаль конкурсларда, мәктәп укучылары ярышларында белем алучыларның катнашу нәтиҗәлелеге | төбәк дәрәҗәсендәге математика, табигый-фәнни һәм технологик профильләр предметлары буенча олимпиадаларда һәм башка интеллектуаль конкурсларда, мәктәп укучылары ярышларында бүләкләнүчеләр һәм җиңүчеләр булу – 100 балл;<br>төбәк дәрәҗәсендәге математика, табигый-фәнни һәм технологик профильләр предметлары буенча олимпиадаларда һәм башка интеллектуаль конкурсларда, мәктәп укучылары ярышларында бүләкләнүчеләр һәм җиңүчеләр булмау – 0 балл; | 10 |
| 3. | Бөтенроссия дәрәҗәсендәге | бөтенроссия дәрәҗәсендәге математика, табигый-фәнни һәм | 10 |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | математика, табигый-фәнни һәм технологик профильләр предметлары буенча олимпиадаларда һәм башка интеллектуаль конкурсларда, мәктәп укучылары ярышларында белем алучыларның катнашу нәтиҗәлелеге | технологик профильләр предметлары буенча олимпиадаларда һәм башка интеллектуаль конкурсларда, мәктәп укучылары ярышларында бүләкләнүчеләр һәм җиңүчеләр булу – 100 балл;<br>бөтенроссия дәрәҗәсендәге математика, табигый-фәнни һәм технологик профильләр предметлары буенча олимпиадаларда һәм башка интеллектуаль конкурсларда, мәктәп укучылары ярышларында бүләкләнүчеләр һәм җиңүчеләр булмау – 0 балл; | |
| 4. | Халыкара дәрәҗәдәге математика, табигый-фәнни һәм технологик профильләр предметлары буенча олимпиадаларда һәм башка интеллектуаль конкурсларда, мәктәп укучылары ярышларында белем алучыларның катнашу нәтиҗәлелеге | халыкара дәрәҗәдәге математика, табигый-фәнни һәм технологик профильләр предметлары буенча олимпиадаларда һәм башка интеллектуаль конкурсларда, мәктәп укучылары ярышларында бүләкләнүчеләр һәм җиңүчеләр булу – 100 балл;<br>халыкара дәрәҗәдәге математика, табигый-фәнни һәм технологик профильләр предметлары буенча олимпиадаларда һәм башка интеллектуаль конкурсларда, мәктәп укучылары ярышларында бүләкләнүчеләр һәм җиңүчеләр булмау – 0 балл | 20 |
| 5. | Математика, табигый-фәнни һәм технологик профильләр предметлары тирәнтен өйрәнелә торган башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүнең мәгариф программаларын гамәли тормышка ашыру нәтиҗәләренең уңай динамикасы | сайлап алуны уздыру датасына кадәрге соңгы өч уку елы өчен математика, табигый-фәнни һәм технологик профильләр предметлары тирәнтен өйрәнелә торган башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүнең мәгариф программаларын гамәли тормышка ашыру нәтиҗәләренең уңай динамикасы булу – 100 балл;<br>сайлап алуны уздыру датасына кадәрге соңгы өч уку елы өчен математика, табигый-фәнни һәм | 30 |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | | технологик профильләр предметлары тирәнтен өйрәнелә торган башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүнең мәгариф программаларын гамәли тормышка ашыру нәтиҗәләренең уңай динамикасы булмау – 0 балл; | |

Заявканы бәяләгәндә кулланыла торган барлык критерийларының әһәмияте күләме суммасы (бәяләү критерийларын барлыкка китерә торган күрсәткечләрне кертеп) 100 процент тәшкил итә.

7.19. Кергән заявкаларны рангларга бүлү, алынган баллар саны тигез булган очракта, заявкаларны бәяләү йомгаклары һәм заявкалар керү чираты буенча алынган баллар кимүгә карап гамәлгә ашырыла.

Сайлап алуда катнашучыларның заявкаларын карап тикшерү һәм бәяләү йомгаклары буенча минималь үтү баллы – 50 балл.

7.20. Сайлап алуны уздыру турындагы белдерүдә күрсәтелгән һәм кергән заявкаларны рангларга бүлү нәтиҗәләре буенча Министрлык тарафыннан төзелгән рейтингта заявкасы беренче урын алган һәм сайлап алуны уздыру турындагы белдерүдә күрсәтелгән һәм бүленгән грант лимиты чикләрендә булган сайлап алуда катнашучы сайлап алуда җиңүче дип таныла.

7.21. Сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсендә әлеге Нигезләмәнең 7.22 пункты нигезендә сайлап алуда катнашучыга бирү өчен каралган грант күләме күрсәтелгәндә, ул сорый торган грант күләме әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән грант күләменә туры килмәгән очракта, конкурс комиссиясе сайлап алуда катнашучыга бирү өчен каралган грант күләменә төзәтмә кертергә мөмкин.

7.22. Сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсе сайлап алуда җиңүчене билгеләү нәтиҗәләре нигезендә бердәм порталда автомат рәвештә булдырыла һәм «Электрон бюджет» системасында конкурс комиссиясе рәисе һәм конкурс комиссиясе әгъзаларының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана, шулай ук бердәм порталда аңа кул куелган көннән соң килә торган эш көненнән дә соңга калмыйча урнаштырыла һәм, сайлап алуда җиңүче билгеләнгән көннән соң килә торган бишенче календарь көннән дә соңга калмыйча, Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырыла. Сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсенә түбәндәге белешмәләр керә:

заявкаларны карап тикшерү датасы, вакыты һәм урыны;

заявкаларын бәяләү датасы, вакыты һәм урыны;

заявкалары карап тикшерелгән сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат;

заявкалары кабул итүдән баш тартылган сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат (аларны кабул итүдән баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп), шул исәптән сайлап алуны уздыру турындагы белдерүнең мондый заявкалар туры килми торган нигезләмәләре;

заявкаларны бәяләү эзлеклелеге, заявкаларны бәяләүнең күздә тотылган һәр

критерие буенча заявкаларга бирелгән күрсәткечләр, заявкаларны бәяләү нәтиҗәләре нигезендә мондый заявкаларга тәртип саннарын бирү турында кабул ителгән карар;

килешү төзелә торган грант алучының исеме һәм аңа бирелә торган грантның күләме.

Сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсенә үзгәрешләр кертү, мондый үзгәрешләр кертелү сәбәпләре күрсәтелеп, әлеге пунктның беренче абзацында билгеләнгән аны формалаштыру тәртибендәге кебек тәртиптә әлеге беркетмәнең яңа версиясен формалаштыру юлы белән сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсенең беренче версиясенә имза куелган көннән 10 календарь көннән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

## VIII. Килешүләр төзү һәм грант күчерү тәртибе

8.1. Министрлык тарафыннан сайлап алу нәтиҗәләре буенча сайлап алуда җиңүче белән Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип форма нигезендә сайлап алуда җиңүче билгеләнгәннән соң 15 эш көненнән дә соңга калмыйча килешү төзелә.

Килешү «Электрон бюджет» системасында электрон документ рәвешендә төзелә һәм һәр як исеменнән эш итәргә хокуклы затларның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имза куела.

Килешүдә билгеләнгән күләмдә грант бирү мөмкинлеге булмауга китерә торган бюджет йөкләмәләренең Министрлыкка элек җиткерелгән лимитлары кимегән очракта, килешүгә килешүнең яңа шартларын килештерү турында яки яңа шартлар буенча уртак фикергә ирешелмәгәндә килешүне өзү турында шарт кертелә.

Килешүгә грант алучының, грант алучы белән (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән, устав (җыелма) капиталларында әлеге ширкәтләрнең һәм җәмгыятьләрнең катнашуында коммерция оешмаларыннан тыш) төзелгән шартнамәләр (килешүләр) нигезендә акча алучы затларның үзләренә карата Министрлык тарафыннан грант бирү тәртибе һәм шартлары (шул исәптән грант бирү нәтиҗәсенә ирешү өлешендә) үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыруга, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерүгә ризалыгы кертелә.

Кирәк булганда Министрлык грант алучы белән Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип формалар нигезендә килешүгә өстәмә килешү, шул исәптән килешүне өзү турында өстәмә килешү төзи.

8.2. Грант алучы кушылу, кушу яисә үзгәртеп оештыру рәвешендә үзгәртеп оештырылганда, килешүгә йөкләмәдә зат алышыну өлешендә килешүгә өстәмә килешү төзү юлы белән үзгәреш кертелә, килешүдә хокук варисы булып торган юридик зат күрсәтелә.

Грант алучыны бүлү, аерып бирү рәвешендә үзгәртеп оештырганда, шулай ук грант алучы бетерелгәндә килешү, берьяклы тәртиптә килешүне өзү турында хәбәрнамә булдырып һәм, грант алучы тарафыннан үтәлмәгән, финанс белән тәэмин

итү чыганагы грант булган йөкләмәләр һәм грантның файдаланылмый калган өлешен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару турында мәгълүматны чагылдырып, килешү буенча йөкләмәләрне үтәү турында акт төзеп өзелә.

8.3. Министрлык, сайлап алуда җиңүченең сайлап алуны уздыру турында белдерүдә күрсәтелгән таләпләргә туры килмәү факты ачыкланган очракта яисә сайлап алуда җиңүче тарафыннан дөрес булмаган мәгълүмат бирелгән очракта, сайлап алуда җиңүче белән килешү төзүдән баш тартырга мөмкин.

8.4. Министрлык әлеге Нигезләмәнең 8.3 пунктында каралган нигезләр буенча сайлап алуда җиңүче белән килешү төзүдән баш тарткан, сайлап алуда җиңүче килешү төзүдән баш тарткан, сайлап алуда җиңүче тарафыннан сайлап алуны уздыру турында белдерүдә билгеләнгән срокта килешүгә имза куелмаган очракта, Министрлык җиңүче дип танылган сайлап алуда катнашучыдан соң заявкалар рейтингында заявкасы кими бара торган тәртиптә килә торган сайлап алуда катнашучы белән килешү төзи.

8.5. Сайлап алуны уздыру турында белдерүдә күрсәтелгән срокларда грант алучы исеменнән эш итәргә хокуклы затның килешүгә кул куюы тәэмин ителмәгән очракта, грант алучы килешү төзүдән баш тарткан дип таныла.

8.6. Грант алучы, шулай ук грант алучы белән төзелгән шартнамәләр (килешүләр) нигезендә акчалар алучы башка юридик затлар тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетыннан алынган чит ил валютасы акчалары исәбеннән, югары технологияле импорт җиһазларын, чималны һәм комплектлаучы әйберләрне сатып алганда (китергәндә) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операциялардән тыш, акчалар алу тыела.

8.7. Министрлык, сайлап алуны уздыру турындагы белдерүдә билгеләнгән килешүләр төзү тәгәлләнү срогы көненнән алып бишенче эш көненнән дә соңга калмыйча, Министрлыкның боерыгы белән рәсмиләштерелә торган грант алучыга грант бирү турында яисә грант бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

8.8. Грант алучыга грант бирүдән баш тарту өчен нигезләр:

грант алучы тарафыннан тапшырылган документларның әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки әлеге документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

грант алучы тарафыннан бирелгән мәгълүматның дөрес булмавы фактын билгеләү.

Грант бирүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, Министрлык, грант алучыга грант бирүдән баш тарту турында карар кабул ителгән көннән алып биш календарь көн эчендә грант бирүдән баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, тиешле грант алучыга хәбәрнамә җибәрә һәм җиңүче дип танылган сайлап алуда катнашучыдан соң заявкасы рейтинг кимү тәртибендә килгән сайлап алуда катнашучы белән килешү төзи.

8.9. Министрлык, грант бирү турында карар кабул ителгән көннән 10 нчы эш көненнән соңга калмыйча, акчаны грант алучы тарафыннан Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яки кредит оешмаларында ачылган исәп-хисап яки корреспондент счетларына күчерүне гамәлгә ашыра.

## IX. Хисаплылык бирү, грант бирү шартларының һәм тәртибенең үтәлешен контрольдә тотуны (мониторинглауны) гамәлгә ашыру тәртибе һәм аларны бозган өчен җаваплылык

9.1. Грант алучы квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның 15 көненнән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән килешүнең бертип формасына теркәлә торган формалар буенча грант бирү нәтиҗәсе күрсәткечләренә ирешү турында хисап һәм финанслар белән тәэмин итү чыганагы грант булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап тапшыра.

9.2. Министрлык әлеге Нигезләмәнең 9.1 пунктында күрсәтелгән хисапларны алар тапшырылган көннән алып биш эш көненнән артмаган срок эчендә тикшерүне башкара.

9.3. Килешүдә билгеләнгән грант бирү нәтиҗәсенең күрсәткеченә ирешүне һәм грант бирү нәтиҗәләрен алу буенча тиешле чара тәмамлану фактын чагылдыра торган вакыйгаларны (контроль нокта) мониторинглау Министрлык тарафыннан Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган нәтиҗәгә ирешүне мониторинглауны уздыру тәртибендә билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча уздырыла.

9.4. Министрлык грант алучының грант бирү шартларын һәм тәртибен, шул исәптән грант бирү нәтиҗәсенә ирешү өлешендә үтәвен тикшерә.

Дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрә.

9.5. Бирелгән грант Министрлыкның тиешле таләбе алынган көннән календарь көннәрдә исәпләнә торган 30 көн эчендә түбәндәге рәвештә Татарстан Республикасы бюджеты керменә кире кайтарылырга тиеш:

тулы күләмдә – грант алучы тарафыннан грант биргәндә билгеләнгән, шул исәптән Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары үткәргән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган шартлар бозылган очракта, шулай ук грант бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешелмәгән очракта;

максатчан билгеләнеше буенча файдаланылмаган грант күләмендә – грант акчасыннан максатчан файдаланмау ачыкланган очракта;

9.6. Финанс белән тәэмин итү чыганагы грант булган акчаның хисап финанс елында файдаланылмый калган өлеше, хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленнән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы бюджеты керменә кире кайтарылырга тиеш.

9.7. Әлеге Нигезләмәнең 9.5 һәм 9.6 пунктында күрсәтелгән акча Татарстан Республикасы бюджеты керменә ирекле рәвештә кире кайтарылудан баш тартылган очракта, алар Министрлык тарафыннан эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә Россия Федерациясе законнары нигезендә мәҗбүри тәртиптә түләтелергә тиеш.